ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында гражданнарның эконом классны торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында гражданнарның эконом классны торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2012 елның 28 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге Закон “Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында” 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү федераль фондының (алга таба – Фонд) эконом классны торак төзү өчен, кысаларында шул исәптән эконом классны торак төзү күздә тотыла торган территорияне комплексны үзләштерү өчен түләүсез файдалануга яисә арендага (алга таба – эконом классны торак төзү өчен түләүсез файдалану яисә аренда), шулай ук эконом классны торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен, кысаларында шул исәптән эконом классны торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү һәм башка торак төзелеше күздә тотыла торган территорияне комплексны үзләштерү өчен арендага (алга таба – эконом классны торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен аренда) тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче, эконом классны торакка кертү шартларына туры килә торган күпфатирлы йортларда һәм (яисә) блоклы төзелә торган торак йортларда торак урыннар, индивидуаль торак йортлар (алга таба – эконом классны торак) сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү кагыйдәләрен һәм күрсәтелгән гражданнарны Фондның эконом классны торак төзү өчен түләүсез файдалануга яисә арендага, шулай ук эконом

классллы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен арендага тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом классллы торак сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләренә (алга таба – исемлек) кертү тәртибен, аерым алганда, чиратын билгели һәм “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 21 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның эконом классллы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала.”;

2) 2 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктында “вакытлыча” сүзен төшереп калдырырга;

3) 6 статьяның 1 – 3 һәм 6 өлешләрендә “вакытлыча” сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 елның 1 июле
№ 44-ТРЗ